# СУГЫШ УРЛАГАН БАЛАЧАК

**Бөек Җиңү һәм аны яулап алган фронт һәм тыл каһарманнарының якты истәлеге халык күңелендә мәңге яшәр. Әдәбият дәресендә яраткан язучыбыз Мөхәммәт Мәһдиевнең "Без – кырык беренче ел балалары" әсәрен укыгач, 6нчы А сыйныф укучыларына әби-бабалары белән шул темага сөйләшү тәкъдим ителде. Түбәндә аларның истәлекләре кыскартып бирелә.**

**Әлфия ЗАҺИДУЛЛИНА, укытучы.**

Минем дәү әтиемә – Сибгатуллин Галимҗанга сугыш башланганда 7 яшь була. Әтиләре сугышка киткәндә: "Күрше апа, улларым ашарга сорап керсәләр, зинһар, буш чыгарма", – дип әйтеп калдыра. Әниләре аларны берүзе тәрбияләп үстерә. Әтиләренә Җиңү көнен күрү насыйп булмый. Аларга ятимлекне, ачлык-ялангачлыкны, шул елларның бик күп авырлыкларын кичерергә туры килә. Алабута ипие, бәрәңге белән тамак туйдыралар. Үсмерләр генә булсалар да тормыш арбасына бик иртә җигеләләр, иртәдән кичкә кадәр колхоз эшеннән кайтып кермиләр. Бөек Җиңүне 67нче тапкыр билгеләп үтсәк тә, дәү әтием әле һаман да ул вакытларда күргән нужаларны хәтерли. Сугышны үз башларыннан кичерүчеләргә, ул елларның авырлыгын үз җилкәләрендә күтәрүчеләргә карата яшь буын һәрчак рәхмәтле һәм хөрмәтле булсын иде, ди дәү әтием.

**Адель ӘСКӘРОВ.**

Әбием Гайнелҗиһан Газизова 1929 елда туган. Аңа 6 класс белем белән генә калырга туры килә. Сугышка кадәр үк өйләре янган була. Болай да авыр тормышлары тагын да кыенлаша. Бер-бер артлы дүрт абыйсы сугышка китеп бара, шуларның берсе кире әйләнеп кайтмый. Бу авыр кайгыны күтәрә алмыйча, әниләре үлеп китә.

Балигълык яшенә җиткәнче үк урман кисүләрен, күргән авырлыкларын ул күз яшьләре белән искә ала. Әбием хәзерге көнгә шөкерана кылып яши, үзләре кичергәннәрне киләчәк буынга беркайчан да күрергә язмасын дип догалар укый.

**Ләйсән ЗИННӘТУЛЛИНА.**

дә килде, тора-бара тормышлар да әйбәтләнде. Хәзерге көнебезнең кадерен белеп яшәргә генә кирәк", – ди ул. Алар дәү әнием белән, ни аяныч, ул инде мәрхүм, биш бала тәрбияләп үстерәләр. Бабаем хәзер балалары, оныклары тәрбиясендә кадер-хөрмәттә яши.

**Алия ГАЛИЕВА.**

хатын-кызлар чәчүлек орлыкны капчыклап җилкәләренә күтәреп ташыдылар. Күргән авырлыкларны әйтеп тә, сөйләп тә бетерерлек кенә түгел".

Шәхси хуҗалыкларында мал-туар асрамасалар да, дәүләткә сөт, йомырка, атланмай заданиесе түләткәннәр. Шул елларның авырлыкларына түзгән дәү әнием хәзерге тормыштан бик тә канәгать. Дәү әтием белән алар җиде бала үстергәннәр. Хәзер ул 13 оныгын һәм 3 оныкчыгын тәрбияләүдә булыша.

**Алинә ЙОСЫПОВА.**

Яраткан дәү әниемнең – Роза Фәйзуллинаның балачагы сугыштан соңгы авыр елларга туры килә. Ул үзеннән кече туганнарын караруда булыша. Бала арбасы тартып әнисе белән уракка баргач, чүмәлә төбенә утырып, кечкенә учына арыш уып ашаганнарын искә төшерә. Һәм шунда өлкәннәрнең матур эшләрен, акыллы сүзләрен үзенә үрнәк итеп алган.

Язын колхоз кырыннан өшегән бәрәңге җыеп алып кайта торган булганнар. Җәен урманнарга йөргәннәр, төрле үләннәр, җиләк, чикләвек җыйганнар. Халык ул елларда бик тә ярдәмчел булган, бер-беренең хәленә кереп, тапкан ризыгын уртаклашып яшәгән.